ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.02.2021 г. № 97

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 31 июлендәге 604 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын көтелгән үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегиясе беркетмәсенең 24 пунктын үтәү йөзеннән, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 31 июлендәге 604 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә (1 нче кушымта):

21 пунктның дүртенче абзацында «1)» номерын «3)» номерына алмаштырырга;

21 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) салым органыннан Хуҗалык алып баручы субъектка карата салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча түләнергә тиешле бурычлар булуын таныклаучы ведомствоара соратуга мәгълүмат килүе.»;

22 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күрсәтелгән гариза нигезендә Башкарма комитет, мондый гариза кергән көннән алып, 20 эш көне эчендә, хуҗалык алып баручы субъект гаризасының әлеге

тәртипнең 20 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә, шул исәптән Хуҗалык алып баручы субъектка карата салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча түләнергә тиешле бурычлар булмавы турында ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында мәгълүмат соратып ала. Тикшерү тәмамланганнан соң, Башкарма комитет урнаштыруга Шартнамә төзү яки урнаштыруга Шартнамә төзүдән баш тарту турында карар кабул итә.»;

30 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

4) Хуҗалык алып баручы субъектның салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле үтәлмәгән йөкләмәләре булган очракта.».

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов